# Дартс



Фейгельман Андрей

# Дартс

- Дартс (инг. darts - дротиклар, яки кыска саплы сөңгеләр, уклар) — стенага эленгән махсус түгәрәк мишеньгә дротиклар ату хас булган уен, дөресрәге уеннар төркеме. Элегрәк мишеньнәр һәм дротиклар төрле булса, хәзерге заманда дартс уены стандартлаштырылган, кагыйдәләре һәм мишене билгеләнгән. Дартс буенча төрле халыкара ярышлар уздырыла, аны үстерүдә төрле оешмалар, федерацияләр эшли, шулай итеп уен бары тик күңел ачу чарасыннан тулы хокуклы спорт төренә әверелә.



Дартс мишене — дротиклар ыргытыр өчен санлы секторларга бүленгән түгәрәк.Егерме радиаль секторга 1 дән 20 гә кадәр саннар бирелгән. Мишень үзәгендәге түгәрәк «Булл-ай» (инг. bull’s eye — үгез күзе) дип атала. Аны кыскача «Булл» дип кенә дә йөртәләр. Ул 50 санын йөртә.Яшел боҗра булл-ай тирәли урнашкан (25 саны).Эчке тар боҗра сектор санын өчкә тапкырлый һәм «требл» дип атала.Тышкы тар боҗра сектор санын икегә тапкырлый һәм «дабл» дип атала. Мишеньнәрнең тимерчыбыклары секторларны аера һәм формасы буенча төрле була: Гади (түгәрәк) тимечыбыкларның дротикларны кире кагу проценты зур. Алар җүнрәк мишеньнәрдә очрый. Өчьяклы тимерчыбыкларга дротик эләксә шуып барыбер мишеньгә кадала. Профессионал мишеньнәрдә аеруча нәзек тимерчыбыклар кулланалар. Аларның бәяләре чагыштырмача кыйбат, ләкин дротиклар мишеньгә эләгеп кире төшү проценты бик аз.



- Дротиклар — дартс уенында кулланыла торган кыска уклар. Аларның озынлыгы 30,5 см (12 дюйм), ә авырлыгы 50 г артмаска тиеш. Авырлыклары буенча дартс уклары өч төргә бүленәләр: авыр дротиклар (29 граммнан авырырак), уртача авырлыктагы дротиклар, җиңел дротиклар (20 граммга кадәр).Хәзерге заманда, гадәттә, 15-40 граммлы дротикларны кулланалар. Спортчыларның осталыгы арткан саен, алар җиңелрәк дротикларга күчәләр, чөнки оста өчен түбән массалы объетларны контрольдә тоту җиңелрәк. Яңа уенчыларда дротикны тыю хисе осталар белән чагыштырганда әзрәк, шуңа күрә аларга авырырак дротиклар куллану киңәш ителә.



# Гомуми кагыйдәләр

- Уенчы дротикны баскан килеш ыргытырга тиеш. Физик хәләт (гариплек) буенча бу кагыйдәне үтәп булмаса, башка позициядән дә (мәсәлән, инвалид креслага утырып) ыргытырга ярый.Уенчы бер-бер артлы берәр дротик ыргытырга тиеш. Ыргытулар сериясе 3 дротиктан тора. Лэг, сет яки матч әзерәк ыргытулар белән дә тәмамланырга мөмкин.Әгәр уенчы мишеньдә булган берәр дротикка тотынса, серия тәмаланган дип санала.Дротик мишеньгә кадалмыйча төшсә, ул саналмый һәм яңадан бәрелми.Уенчыларга дротиклар атканда брусокка басырга һәм аны узарга ярамый.



# Уеннар

- 501 (301)ҮзгәртүҺәр як уенны 501 (301) исәбе белән башлый. Шул санны киметеп нульга җиткергән уенчы җиңә. Уен «дабл» яки «булл-ай» секторларына бәрелеп тәмалануы мәҗбүри. Әгәр уенчы соңгы бәреше белән нульны узса, яисә исәбе бер санына тиң булса, соңгы сериянең бөтен ыргытулары саналмый һәм уен моңа кадәрге исәп белән дәвам итә. Һәр 301 уены «лэг» дип атала. Биш «лэг» бер «сет»ны тәшкил итәләр. Уен өч «сет»та җиңүгә кадәр дәвам итә. Алдан билгеләнгән «сетлар» санында өскә чыккан уенчы җиңүче була.
- Мән
- Бу уенда булл-айга һәм яшел боҗрага эләгү генә санала. Уенчылар серияләп атып 1000 санын җыярга тиешләр. Артыгын җыю, шулай ук, серияне юк итә. Беренче итеп 1000не җыйган кеше ота.
- Раунд

Уенчылар дротикларны рәттән 1 алып 20 секторларга, алардан соң 20нче секторның «дабл»ына һәм «требл»ына, уенны тәмамлап Булл-айга аталар. Уенчы үз сериясендәге бөтен өч атуында да максатына ирешсә, ул атуын дәвам итә. Җиңүче булып беренче итеп бөтен секторларны үтеп булл-айга эләккән уенчы билгеләнә.

- Биш гомер

ҮзгәртүӨч дротик ыргытып моңа кадәр ыргыткан уенчыдан бергә булса да күбрәк сан җыярга кирәк. Чыгарма булып 180 саны тора. Һәр уенчы биш тапкыр ялгыша ала. Бу уенны биш – алты кеше белән уйнарга яхшырак.

